КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 22 сентябрь г.Казань № 1176

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк дәүләт торак контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 936 нчы карары белән расланган Төбәк дәүләт торак контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк дәүләт торак контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 936 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 28 февраль, 179 нчы, 2022 ел, 13 август, 810 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Төбәк дәүләт торак контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт торак күзәтчелеге объектлары булып Россия Федерациясенең торак законнарында, энергияне сак тоту турында Россия Федерациясе законнарында һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында, Россия Федерациясендә торак фондына карата газ белән тәэмин итү турындагы законнарда билгеләнгән мәҗбүри таләпләр үтәлергә тиешле эшчәнлек, гамәлләр (гамәл кылмау) тора, муниципаль торак фондыннан, гражданнардан, юридик затлардан, шәхси эшмәкәрләрдән тыш (алга таба - контрольдә тотыла торган затлар, мәҗбүри таләпләр), шул исәптән:

торак милекчеләре ширкәтләре;

торак һәм торак-төзелеш кооперативлары;

ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар;

каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторлары;

күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне тоту һәм ремонтлау буенча хезмәт күрсәтүче һәм (яисә) эшләр башкаручы юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар;

йорт эчендәге һәм (яисә) квартал эчендәге газ җиһазларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау эшчәнлеген гамәлгә ашыручы махсуслаштырылган оешмалар;

төтен һәм вентиляция каналларының торышын һәм эшләвен тикшерү, аларны чистарту һәм ремонтлау эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларны;

күпфатирлы йортларда лифтларны эксплуатацияләү эшчәнлеген гамәлгә ашырганда бер яисә берничә эш төрен башкару, шул исәптән аларга хезмәт күрсәтү һәм ремонт эшләрен башкару эшчәнлек предметы булган оешмалар.

Дәүләт торак күзәтчелеге объекты булып лицензия нигезендә күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оештыру-хокукый формага яисә индивидуаль эшкуарларга бәйсез рәвештә юридик затларның эшчәнлеге, гамәлләре (гамәл кылмавы) тормый.»;

7 пунктка түбәндәге эчтәлекле «м» пунктчасы өстәргә:

«м) йорт эчендәге һәм (яки) фатир эчендәге газ җиһазын куркынычсыз эксплуатацияләүгә һәм аларга техник хезмәт күрсәтүгә карата таләпләрнең, шулай ук күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәт дип каралган вентиляция һәм төтен каналларын карап тотуга карата таләпләрнең.»;

әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтаның беренче абзацында «энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында» сүзләреннән соң «, Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында законнар» сүзләрен өстәргә;

әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Төбәк дәүләт торак контроле
(күзәтчелеге) турында нигезләмәгә
3 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 22 сентябрь, 1176 нчы
карары редакциясендә)

Дәүләт торак контролен гамәлгә ашырганда планнан тыш тикшерүләр үткәрү кирәклеген билгеләү өчен кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары

1. Күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре булган гражданнардан (мөрәҗәгать иткән гражданның шәхесен ачыкларга мөмкинлек биргән ысул белән) яисә күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре булган оешмалардан, күпфатирлы йорттагы урыннардан файдаланучы гражданнардан Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе адресына кергән алдагы календарь елның шул ук чоры белән чагыштырганда вакыт берәмлеге (ай, квартал) өчен мөрәҗәгатьләр, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, контрольдә тотыла торган затлар тарафыннан Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозу фактлары турында дәүләт мәгълүмат системаларыннан мәгълүмат санының өч мәртәбә һәм аннан да күбрәк үсеше (алга таба - Инспекция).

2. Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында Россия Федерациясе Торак кодексының 165 статьясындагы 5 өлеше нигезендә билгеләнгән урнаштыру тәртибе, рәвешләре, сроклары һәм вакыты нигезендә урнаштырылырга тиешле мәгълүматны өч һәм аннан артык ай дәвамында актуальләштерүнең булмавы.

3. Өч ай рәттән Инспекциягә күпфатирлы йорт бүлмәләре милекчеләренең шундый ук көн тәртибе мәсьәләләре буенча карарлардан гыйбарәт ике һәм аннан күбрәк гомуми җыелыш беркетмәләре керү.

4. Өч ай дәвамында гражданнан яки күпфатирлы йорт бүлмәләре милекчеләре булган оешмадан, күпфатирлы йорт бүлмәсеннән файдаланучы гражданнан алынган белешмә (мәгълүмат), дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан алынган мәгълүмат һәм торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында контрольдә тотылучы зат тарафыннан урнаштырылган мәгълүмат туры килми торган (дөрес булмаган) биштән артык факт ачыклану.